Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2022-2023 нче уку елы
8 нче сыйныф

Эш вакыты – 120 минут
Гомуми балл – 70

1. Океаннар, диңгезләр белән юылу буенча Россия кайсы дәүләт белән тиңләшә? *(2 БАЛЛ)*
а) Канада в) Төркия
б) Япония г) Австралия

2. Борынгы тау ясалу чорында, иң элек кайсы территория барлыкка килгән? *(2 БАЛЛ)*
а) Себер платформасының утырма катламы в) Себер платформасы нигезе
б) Байкал буе таулары г) Урал таулары

3. Ерым һәм балкалар иң күп булган урын: *(2 БАЛЛ)*
а) Валдай калкулыгы в) Урта Рус калкулыгы
б) Каспий буе түбәнлеге г) Идел буе калкулыгы

4. Тын океаныныңРоссия климатына йогынтысы аеруча сизелә торган вакыты: *(2БАЛЛ)*
а) җәй б) кыш в) яз г) көз

5. Россия климатының континентальлеге кайсы юнәлештә үзгәрә?*(2БАЛЛ)*
а) көнбатыштан көнчыгышка в) төньяктан көньякка
б) көнчыгыштан көнбатышка г) көньяктан төньякка

6. XVI-XVII гасырларда Россиянең бердәнбер порты булган. Ул кайсы шәһәрдәге порт? *(2 БАЛЛ)*
а) Мурманск в) Владивосток
б) Архангельск г) Санкт-Петербург

7. Елгаларны авышлыклары түбәнәю тәртибендә языгыз. *(2 БАЛЛ)*
а) Обь б) Идел в) Енисей

8. Туфракта гумус барлыкка килүдә түбәндәге үсемлек калдыкларының әһәмияте зур: *(2 БАЛЛ)*
а) мүк һәм лишайниклар в) яфраклы агачлар
б) ылыслы агачлар г) үләннәр

9. Тундра зонасының көньягы экваторга якынрак булган урын: *(2 БАЛЛ)*
а) Көнчыгыш Европа тигезлеге
б) Көнбатыш Себер тигезлеге
в) Урта Себер яссы таулыгы

10. Иң күп сусаклагычлар: *(2 БАЛЛ)*
а) Иделдә в) Анагарада
б) Обьта г) Енисейда

11. Суының тозлылыгы арта бару нәтиҗәсендә экологик проблема тудыручы диңгез *(2 БАЛЛ)*
а) Балтыйк в) Азов
б) Кара г) Каспий

12. Кислоталы явым-төшемнәр еш була торган урыннар: *(2 БАЛЛ)*
а) Төньяк Кавказ һәм Урал
б) Урал һәм Үзәк Россия
в) Үзәк Россия һәм Көнбатыш Себернең көньягы
г) Көнбатыш Себер көньягы һәм Ерак Көнчыгыш

13. Тайга зонасында яши торган кошлар: *(2 БАЛЛ)*
а) суер (глухарь) һәм көртлек (тетерев)
б) көртлек (тетерев) һәм мәче башлы ябалак (сова)
в) мәче башлы ябалак (сова) һәм байгыш (филин)

14. Тайга зонасының зур өлешен били торган агач: *(2 БАЛЛ)*
а) эрбет (кедр) в) нарат (сосна)
б) чыршы (ель) г) карагай (лиственница)

15. Россиядә карьер ысулы белән табыла торган казылма байлык:
(2 БАЛЛ)
а) бары тик көрән күмер
б) көрән күмер һәм тимер рудалары
в) көрән күмер, тимер рудалары һәм бакыр рудалары

16. Елгаларда су басулар булмасын өчен иң әһәмиятле чара ул:
(2 БАЛЛ)
а) сазлыкларны киптерү
б) урманнарны кисү
в) урманнарны саклау һәм кыр ышыклау урман тезмәләре (полоса) булдыру
г) грунт сулары тигезлеген түбәнәйтү

17. Түбәндәге раслауларның кайсысы дөрес, шуны билгеләп, санны күрсәтегез.
1. Россиянең территориясе 10 сәгать поясына бүленгән.
2. Россиянең территориясе 85 субъекттан тора.
3. Россиянең чикләре – дөнья күләмендә иң озын чикләр.
4. Россия көнбатыштан көнчыгышка таба 4000 км, ә төньяктан көньякка таба10 000 км.
5. Россиянең иң көньяк ноктасы – Кушка шәһәре.

18. Түбәндәге климат поясларының кайсысы Россия территориясендә юк?
(2 БАЛЛ).
1. арктика 3. уртача
2. тропик 4. субтропик

19. Түбәндәге раслауларның кайсылары дөрес дип саныйсыз? *(2 БАЛЛ)*
1. Россиянең гаять зур территориясе Төньяк Боз океаны бассейнына карый.
2. Россия территориясендә җир асты сулары чыганакларын тикшерү саны 4000 гә җитә.
3. Россиядә генә түгел, ә дөнья күләмендә, соры урман туфраклары иң яхшы туфрак булып санала.

20. Россиянең кайсы урынында һәм кайсы вакытта кояшны төньяк юнәлештә күреп була? *(10 БАЛЛ)*
_____
_____

21. Дөрес җавапларны туры китерегез *(2 БАЛЛ)*.

Таулар	***Яше***
1. Кавказ	А. Яңадан барлыкка килгән
2. Тянь-Шань	Б. Яшәргән
3. Урал	В. Яшь

22. Россиядә иң күп явым-төшемнәр башлыча кайсы ел фасылында күзәтелә? *(2 БАЛЛ)*
1. кышын 3. язын
2. җәен 4. көзен

23. Әлеге сурәтләүдән чыгып, җавапны табыгыз *(10 БАЛЛ)*.

1937 нче елда өч очучы: В.П. Чкалов, Г.Ф. Байдуков, А.В. Беляков, бер самолетка утырып очып китәләр. Аларның очыш маршруты төньякка таба була. Очкычның приборлары бик төгәл эшли, компас угы бары тик төньякны гына күрсәтә. Бераз вакыттан соң, очкычның компас угы кинәт кенә төньяк урынына бары тик көньякны күрсәтә башлый. Югыйсә приборлар да төзек була, компас та бик төгәл эшли.
Бу нилектән шулай булган?
_____
_____
_____
_____
_____
_____